ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3 ноябрь, 2021 ел № 9/9

Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясына, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номеры Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/11, 2019 елның 25 февралендәге 30/6, 2019 елның 1 августындагы 32/11, 2020 елның 17 июнендәге 40/6, 2021 елның 18 мартындагы 6/12 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 6 пунктта түбәндәге эчтәлекле 45, 46 пунктчалар өстәргә:

«45) яктыртуның ачык ысулы – мәгълүмат конструкциясен яктыртуның яктылык чыганагыннан яктылыкның каршылыкларсыз тарату ысулы;

46) рекреацион билгеләнештәге җирләр – гражданнарның ялын, туризмны, физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт эшчәнлеген оештыру өчен кулланылучы җирләр.»;

2) 9.14 пунктында:

- 1 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

- 2, 3 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) контейнерлардан һәм махсус билгеләнгән урыннардан тыш, металл, төзелеш, көнкүреш калдыкларын һәм башка чүп-чарны, агач, автомобильләрнең запас өлешләрен, покрышкалар җыю һәм саклау;

3) Башкарма комитет белән килештермичә, билгеләнгән тәртипне бозып, стационар булмаган сәүдә объектларын, шулай ук капиталь булмаган стационар

булмаган корылмалар, төзелмәләр (аттракционнар, кабартылган батутлар, велосипедлар, роликлар прокаты һәм халыкның ялын һәм күңел ачуын оештыру өчен кулланыла торган башка шундый объектлар) урнаштыру һәм эксплуатацияләү;

- түбәндәге эчтәлекле 21-26 пунктчалар белән тулыландырырга:

«21) стационар булмаган объект янында проектта каралмаган өстәмә җиһазлар (суыткыч витриналары һ.б.) урнаштыру, шулай ук куллану базарының сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты янына өстәлләр, зонтиклар урнаштыру, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамә белән билгеләнгән мәйдан чикләрендәге җәмәгать туклануы объектларыннан тыш.»;

22) төзекләндерү элементларында һәм стационар булмаган сәүдә объекты янәшәсендәге территориядә товар, төрү материаллары, чүп-чар җыю;

23) тротуарларны, җәяүлеләр юлларын, газоннарны, төзекләндерү элементларын транспортны бушату зонасына илтү, товар китерүче автотранспортны кую өчен куллану, шулай ук товарлар сату;

24) өзелгән һәм/яйсә изоляция тышчасы булмаган, буялмаган, коррозия һәм/яки механик зарарлану сыйфатларына ия булган, чыбыклары асылынып торган һәм/яки яктырту баганаларына һәм электр тапшыру линияләренә уралган үткәргечләрне куллану;

25) үткәргечләрдә өзелү, яктырту баганаларында, изоляторларда ватылу билгеләре булганда тышкы яктырту җайланмаларын эксплуатацияләү. Тышкы яктырту җайланмалары эшендә электр чыбыклары өзелү яки терәкләрнең ватылуы белән бәйле җитешсезлекләрне ачыклаганнан соң ук кичекмәстән төзәтергә кирәк.

26) үз белдегең белән чыбыкларны һәм кабельләрне челтәрләргә һәм тышкы яктырту җайланмаларына тоташтыру.»;

3) 9.16 пунктта «гамәлдәге җир законнары, торак урыннар территорияләрен карап тоту санитар кагыйдәләре нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 9.16.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«9.16.1 Идарәче оешмалар – җир участогы чигеннән 5 м ераклыкта яйсә урамның йөрү өлешенә кадәр, әмма 5 м артмаган (объект юл буенда урнашкан очракта) җир участогы»;

5) 61.1, 62 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

6) 63 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) эскәмияләрне каты өслеккә яки фундаментка урнаштырырга кирәк. Ял итү зоналарында, урман паркларында, балалар мәйданчыкларында йомшак катламнарга эскәмияләр урнаштыру рөхсәт ителә. Фундамент булганда, аның өлешләрен җир өслегеннән чыгып тормаслык итеп эшләргә кирәк»;

7) 71 пунктта «тәкъдим ителә» сүзләрен «тиеш» сүзенә алыштырырга;

8) 80 нче пунктта «тәкъдим ителә» сүзләрен «тиеш» сүзенә алыштырырга;

9) 84 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«84) Муниципаль берәмлек территориясендә коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар һәм (яки) чүп савытлары кулланыла.

Гомуми файдалану территорияләрендә чүп савытлары мондый территория хуҗалары тарафыннан куелырга тиеш.

Капиталь төзелеш объектлары янында контейнерлар һәм (яки) чүп савытлары мондый объектларның хуҗалары тарафыннан урнаштырылырга тиеш.

Чүп савытлары куюга таләпләр:

1) җитәрлек биеклектә (максималь 100 см кадәр) һәм күләмдә булуы;

2) куелучы чиләкләр һәм чүп капчыклары куллану, аларны пөхтә итеп урнаштыру.»;

10) 102 пунктта «тәкъдим ителә» сүзләрен «тиеш» сүзенә алыштырырга;

11) 116 пунктта «тәкъдим ителә» сүзләрен «тиеш» сүзенә алыштырырга;

12) 120 пунктның 11 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«11) уемнарны каплаучы һәм өлешчә каплаучы тышкы мәгълүмат чараларын һәм мәгълүмати-басма продукцияне урнаштыру, витриналар, тәрәзәләрне, аркаларны пыялалау, архитектура детальләре һәм биналарда декоратив-сәнгать бизәлеш;»;

13) 122.3 пунктында «булырга мөмкин» сүзләрен «булырга тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

14) 129.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«129.4. Бәйрәм бизәлеше – милли флаглар, лозунглар, гирляндалар, паннолар элүне, декоратив элементлар һәм композицияләр, стендлар, киосклар, трибуналар, эстрадалар урнаштыруны, шулай ук бәйрәм иллюминациясен үз эченә ала.»;

15) 130 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Йорт билгеләрен һәм күрсәтмәләрне, номерларны кую өчен җаваплылык бина милекчесенә, яйсә бина яки корылмага башка законлы нигездә (аренда, хуҗалык алып бару, оператив идарә хокукында һ.б.) ия булган затка, яйсә бинаны эксплуатацияләү өчен җаваплы вазыйфаи затка йөкләнә.»;

16) түбәндәге эчтәлектәге 148.1 пунктын өстәргә:

«148.1. Чүп-чарны җыю һәм объекттан коймаларны вакытында чыгару, җимерелгән каты өслекне торгызу һәм кышкы чорда кире күмелгән яки ордер ябылганнан соң утырган грунтны тәртипкә китерү җир эшләрен башкаручы оешмага йөкләнә. Подрядчы килешүе өзелгән очракта, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен заказчы җавап бирә. Һава шартлары начар булу сәбәпле, язгы чорда җир ишелүне кичекмәстән бетерү мөмкин булмаган очракта, җир эшләре үткәрү урынында вакытлыча тоташ койма куярга һәм уңай һава шартлары туганда, җитешсезлекләрне бетерергә кирәк»;

17) 190 пунктта «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Кама буе территориаль идарәсе белән килештерү буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

18) 207.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«207.1. Муниципаль берәмлек территориясендә таралуны булдырмау максатларында физик һәм юридик затлар, милек хокукында яки яки башка хокукта ия булган җир участокларында, янәшә территорияләрдә (шул исәптән биналар һәм корылмаларның коймалары һәм фасадлары буенда) Сосновский балтырганы, тамырдан таралып үсә торган агач үсентеләре үсүенә юл куймаска тиеш.

1,5 метрга кадәрге биеклектәге тамырдан таралып үсә торган яшь агачлар Башкарма комитет белән килештермичә, физик һәм юридик затлар тарафыннан

киселергә тиеш. 1,5 м дан артык биеклектәге тамырдан таралып үсә торган яшь агачларны кисү Башкарма комитет белән килештереп, агачларны, куакларны тулысынча һәм өлешчә кисүгә, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында каралган тәртиптә башкарыла».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев